РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«24» ноябрь 2020 е. Олы Кайбыч ав. № 21

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы, район Башлыгы урынбасары, Контроль-хисап палатасы рәисе, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы, Башлык урынбасары, Контроль-хисап палатасы рәисе, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү турында» 2020 елның 15 нче июнендәге 242 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы, Башлык урынбасары, Контроль-хисап палатасы рәисе, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү турында» нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы, Башлык урынбасары, Контроль-хисап палатасы рәисе, муниципаль хезмәткәрләр хезмәтенә түләү турында» нигезләмәнең 6 нчы кушымтасын кушымта итеп бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе Р.Г.Айзатулловага йөкләргә.

Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Советы Рәисе
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы,
Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Советы
Рәисе урынбасары Р.Р.Хәялиев

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Советының 2020 елның «24» 11.
21 номерлы карарына кушымта

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы, район Башлыгы урынбасары, Контроль-хисап палатасы рәисе, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында» нигезләмәгә 6 нчы кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгына, Башлык урынбасарына, Контроль-хисап палатасы Рәисенә, Башкарма комитет җитәкчесенә айлык өстәмә акчалата түләүләр күләме**

| Вазыйфа исемнәре | Айлык акчалата түләү күләме |
| --- | --- |
| Башлык | 72858 |
| Башлык урынбасары | 31103 |
| Башкарма комитет җитәкчесе | 20023 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 10057 |